РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕКИБЯКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ул. Ленина, д.31, офис 1**
**село Верхние Кибя-Кози,**
**422083**
**тел.(884360) факс: 56-5-42**
E-mail: VKbk.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ КИБӘХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**Ленин урамы, 31 енче йорт,**
**1 енче офис, Югары Кибәхуҗа авылы, 422083**
**тел. (884360) факс: 56-5-42**
E-mail: VKbk.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318107 ОГРН 1061675010836 ИНН/КПП 1619004443/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№33** **27.08.2025 ел**

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының 2023 елның 23 мартындагы 9 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2025 елның 2 июлендәге 09/13-09/3037 номерлы хатын карап, 1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 89-ФЗ номерлы, 2002 елның 10 гыйнварындагы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 7-ФЗ номерлы, 2009 елның 23 ноябрендәге «Энергияне сак тоту турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 261-ФЗ номерлы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы «Җитештерү һәм куллану калдыкларын тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының 2023 елның 23 мартындагы 9 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» карарына, 4.1. пункт белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«4.1. Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең территориясендә кулланылган терекөмешле лампалар туплану урыны (урыннарын) турында кулланучыларга мәгълүматны әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Кибәхуҗа
авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Мәхмүтов